Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының
Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советы

РЕШЕНИЕ КАРАР
8 октябрь 2019 ел №148

**Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 пункты нигезендә, Сарман муниципаль районының Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. 2019 елның 24 ноябренә Сарман муниципаль районының «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.
2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2020 елда «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 нче һәм II төркем инвалидларыннан һәм өлкәнрәклэрдән (80 яшьтән өлкәнрәк), җирлек территориясендә ел дәвамында яшәмәүче гражданнардан, авыр тормыш хәлендә калган гаилә әгъзаларыннан тыш, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә һәм түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерүгә килешәсезме?:

- Ленин урамы, Җиңүнең 30 еллыгы, Әхмәдиев п. т. Җәлил урамы буенча тротуарларны ремонтлау;

- балалар өчен уен мәйданчыкларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (ком алыштыру, уен җиһазларын ремонтлау һәм буяу, куркынычсызлыкны тикшерү һәм эшкә сәләтлелекне тәэмин итү, документлар төзү, кисәтү аншлаглары урнаштыру), Җәлил ш. т. п., Яңа Минзәләбаш ав.

- бүләкләр алу, Сабантуй, Җиңү көне, Өлкәннәр көне, Инвалидлар көне, Яңа ел бәйрәмнәрен үткәрү өчен туклануны оештыру;

- Җәлил поселогы Абдрахманова, Кызыл Бакча, Яңа Минзәләбаш авылларында өстәмә яктырту нокталары сатып алу һәм урнаштыру;

- Җәлил поселогы, Габдрахманов, Кызыл Бакча, Яңа Минзәләбаш зиратларында зур агачларны кисү, үләннәрне чабу, чүп чыгару;

Дендропарк территориясен һәм Җәлил т. п. бульварын чабу;

- Җәлил т. п. МАФНЫ буяу һәм ремонтлау;

- Җәлил поселогы бульвары территориясендә чүп җыю;

- фонтанга техник хезмәт күрсәтү (электр энергиясе, су белән тәэмин итү, ремонт); ӘЙЕ ЮК?»

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында «PRAVO.TATARSTAN.RU» урнаштырырга һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә һәм «Сарман» газетасында бастырып чыгарырга.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советы Рәисе
«Җәлил шәһәр тибындагы поселогы»
муниципаль берәмлеге башлыгы Р.Ә. Кәримов